РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул.Ленина, д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
20.08.2026

КАРАР
№ 19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының
28.04.2018 №10 карары белән расланган
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле
үзидарә органнары депутатларына,
сайланулы вазыйфаи затларына һәм
муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт
ечен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

07.06.2025 ел №144-ФЗ, Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 135 ст. Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 28.04.2018 ел, №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (Советның 09.11.2020 №10, 20.10.2022 №22, 19.12.2022 №28, 26.08.2024 №12, 13.11.2024 №25, 25.04.2025 №11, 17.12.2025 №16 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.5 нче бүлекнең 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Хезмәткәргә премия күләмен дисциплинар җинаять кылган өчен дисциплинар түләтү кулланылуга бәйле рәвештә киметү хезмәткәргә карата тиешле дисциплинар түләтү кулланылган чор өчен хезмәткәрнең хезмәт хакы составына керә торган премияләргә карата гына гамәлгә ашырыла, ә премияне мондый киметү күләме хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы күләмен 20 проценттан артыграк киметүгә китерә алмый”.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Иске Икшермә авыл
җирлеге Башлыгы А.И.Биккинин